**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 125** **22 ноябрь 2018 ел**

**«Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җирле үзидарә органнарында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, белгечләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 апрелендәге 95 номерлы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына (Югары Пәнәче авыл җирлегенең 2016 елның 14 маендагы 96 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктның 2.11 подпунктында «38,75» санын «56» санына алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Югары Пәнәче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **М.Х.Туктаров**